РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«04» сентябрь 2023 г. Олы Кайбыч ав. № 215

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының аерым карарларын гамәлдән чыгару турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында, Кайбыч муниципаль районы прокурорының 2023 елның 14 июлендәге 02-08-02-2023 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын аренда түләүләрен кичектерүне бирү өлешендә яклау чаралары турында» 2021 елның 17 февралендәге 37 номерлы;

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә ярдәм чаралары турында» 2021 елның 17 февралендәге 38 номерлы;

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә ярдәм чаралары турында» 2021 елның 17 февралендәге 37 номерлы Кайбыч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 маендагы 112 номерлы.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А. И.Рәхмәтуллин